**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**

**Исполнительного комитета Азнакаевского муниципального района**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**Азнакай муниципаль районы башкарма комитеты**

ул. Ленина, д..22, г. Азнакаево, 423330
Тел./факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

Ленин урамы, 22 йорт, Азнакай шәһәре, 423330
Тел./ факс (885592) 7-24-71, 7-26-97
E-mail: aznakay@tatar.ru
adm-aznakay@mail.ru

# ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

**«28» февраль 2020 ел** **№ 58**

2019-2022 елларга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында конкурентлыкны үстерүгә ярдәм итү буенча чаралар планы («Юл картасы») хакында

Татарстан Республикасы Президентының 2019 елның 31 августындагы 306 номерлы «Татарстан Республикасында конкуренцияне үстерүгә ярдәм итү өчен товар базарлары исемлеген һәм 2019 - 2022 елларга Татарстан Республикасында конкуренцияне үстерүгә ярдәм итү буенча чаралар планын («Юл картасын») раслау турында» күрсәтмәсен, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 елның 26 ноябрендәге АП-12-397 номерлы Татарстан Республикасында кокурентлыкны үстерү буенча милли планны гамәлгә ашыру мәсьәләсе буенча киңәшмә беркетмәсен үтәү йөзеннән карар итә:

1. Әлеге карарга кушымта нигезендә, Азнакай муниципаль районында 2019 - 2022 елларга конкуренцияне үстерүгә ярдәм итү буенча чаралар планын («Юл картасы») расларга.
2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Башкарма комитетының 2017 елның 29 декабрендәге 332 нче номерлы«2018-2020 елларга Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районында конкурентлыкны үстерүгә булышлык күрсәтү буенча чаралар планы (»Юл картасы») турында карары үз көчен югалткан дип санарга.
3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча урнаштырырга: http: //aznakayevo. tatar. ru.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче А. Х. Шәмсетдинов